СОВЕТ КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

______________　　　с. Коргуза　　　______________

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В.Плохов мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советы, гамәлдәге законнар үзгәрүгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнде, ул җирлек Советы тарафыннан хупланды, җирлекнең мәгълүмат стендларында игълан ителде, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырылды һәм гавами тыңлауларда җирлек халкы белән барлык кирәкле фикер алышу процедураларын узды дип билгеләп үтә.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131–ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45–ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставы нигезендә

Югары Ослан муниципаль районының
Карагуҗа авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставы статяларвның яңа редакциясен растарга.
3. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В. Плохов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Карагуҗа авыл җирлеге Советының
2024 елның 18 декабреннән
№53-273 карарына

1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Уставның 5 статьясындагы 1 пунктының 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;"

2. Уставның 5 статьясындагы 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 21 пунктча өстәргә:

«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы_Федераль закон, хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»

3. Уставның 19 статьясындагы 5 пунктында «әлеге Уставның 39 статьясындагы 1 пунктының 1 - 7 пунктчаларында билгеләнгән» сүзләрен «әлеге Уставның 40 статьясындагы 1 - 7 һәм 10.1 пунктчаларында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

4. Уставның 29 статьясындагы 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Җирлек Советы депутаты коррупциягә каршы көрәш максатларында федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән булса, җаваплылыктан азат ителә, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү "Коррупциягә каршы тору турында"2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә күрсәтелгән затларга бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип таныла.

5. 40 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктчасы өстәргә:

«10.1) аның чит ил агенты статусын алуы

6. Уставның 43 статьясының 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Җирлек башлыгы коррупциягә каршы көрәш максатларында федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен, әгәр мондый чикләүләрне,

тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән булса, җаваплылыктан азат ителә, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү "Коррупциягә каршы тору турында"2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә күрсәтелгән затларга бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип таныла»;

7. Уставның 49 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар хуҗалык алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык китапларында исәпкә алуны гамәлгә ашыру.».

8. Уставның 49 статьясындагы 1 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

9. Уставның 69 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"69 статья

Муниципаль хокукый актларның үз көченә керүе һәм халыкка җиткерелүе.

1. Җирлек Советы карарлары, әгәр әлеге карар белән башкасы билгеләнмәгән булса, җирлек башлыгы кул куйган көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турындагы хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

Җирлек Советының җирлек Уставын кабул итү яисә әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарлары федераль законда, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Җирлек башлыгының, җирлек Башкарма комитетының, җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларының хокукый актлары, җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр, әгәр актларда башкасы билгеләнмәгән булса, имзаланган көннән үз көченә керә.

3. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль хокукый актлар, гамәлгә куючысы муниципаль район булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары: исеме, имза салу датасы (җирлек Советы тарафыннан кабул ителгән хокукый актлар өчен - шулай ук аны җирлек Советы кабул иткән дата), теркәү номеры, хокукый актка кул куйган вазыйфаи зат исеме булырга тиеш.

5. Җирлек Советының район бюджеты турындагы, хисап турындагы, аның үтәлеше турындагы, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү турындагы карарлары, җирлек Советы Регламенты, җирлек башлыгы, җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе кабул иткән башка норматив хокукый актлар, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларны кабул иткән көннән алып җиде көн эчендә рәсми рәвештә игълан ителергә тиеш.

6. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында

төзелгән килешүне игълан итү дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) «Волжская новь» район газетасында муниципаль хокукый актны рәсми бастырып чыгару;

2) чикләнмәгән затлар даирәсе өчен мөмкин булган урыннарда муниципаль хокукый актны урнаштыру (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр биналарында, йөрергә мөмкин булган башка урыннарда);

3) муниципаль хокукый актны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (verhniy-uslon.tatarstan.ru) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру;

4) муниципаль хокукый актны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру;

7. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне, аның тулы текстын беренче тапкыр «Волжская новь» район газетасына бастыру яисә аның тулы текстын беренче тапкыр Югары Ослан муниципаль районының (verhniy-uslon.tatarstan.ru) рәсми сайтында "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру рәсми бастырып чыгару дип санала.

8. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (verhniy-uslon.tatarstan.ru) "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә чикләнмәгән затлар даирәсе файдалана алырлык урыннарда (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр, килү өчен мөмкин булган башка урыннарда) алар тарафыннан өстәмә техник чаралардан файдаланмыйча бер яисә берничә тоташтыру пункты булдыру тәэмин ителә».

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В. Плохов